**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР №

______________　　　　　　　　　　______________

**Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек Башлыкларының, депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең акчалата түләүләре һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2020 елның 1 октябреннән индексацияләү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек Башлыкларының, муниципаль берәмлек Башлыклары урынбасарларының, депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләүләре күләмнәрен арттыру турында» 6.08.2020 ел, 658 номерлы карары, «Муниципаль берәмлек Башлыкларының, депутатларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата түләүләре күләмнәрен индексацияләү турында» 23.09.2020 ел, 01-06 номерлы карары нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.«Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Актаныш муниципаль районының контроль-хисап органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Актаныш муниципаль районы Советының 2014 елның 15 апрелендәге 38-04 номерлы карары белән расланган, муниципаль берәмлек Башлыкларының, депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладларын 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга (индексацияләргә).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең акчалата түләүләре һәм вазыйфаи окладлары, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләү күләмнәре һәм арттырылганда (индексацияләгәндә) түләүләр арту ягына бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш;

әлеге карарның 1 пунктын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау, тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе К.Р.Каюмовага йөкләргә.

Башлык　　　　　　　　　　Э.Н.Фаттахов